ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июня 2020г. № 2848

2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасы, Татарстан Республикасының «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2016 елның 18 мартында «Челнинские известия» газетасының 19 нчы санында басылып чыккан «2016-2021 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 1078 номерлы;

2) 2016 елның 13 апрелендә «Челнинские известия» газетасының 26 нчы санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 1 апрелендәге 1451 номерлы;

3) 2017 елның 25 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 5 нче санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре

муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 17 гыйнварындагы 85 номерлы;

4) 2019 елның 8 февралендә «Челнинские известия» газетасының 9 нчы санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 апрелендәге 2166 номерлы;

5) 2019 елның 13 февралендә «Челнинские известия» газетасының 10 нчы санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 февралендәге 539 номерлы;

6) 2019 елның 26 июнендә «Челнинские известия» газетасының 45 нчы санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 июнендәге 3189 номерлы;

7) 2019 елның 11 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 91 нче санында басылып чыккан, «Башкарма комитетның 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 декабрендәге 6324 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 15 июнендәге
2848 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. 2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» (алга таба - программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасының «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе исеменнән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе исеменнән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты;<br>Башкарма комитетның районнар хакимиятләре |
| Ярдәмче программаның Дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Дәүләт заказчысы) |
| Программаның максаты | Программаның төп максаты булып билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүдә дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын тормышка ашыру тора. |
| Программаның бурычлары | Яшь гаиләләргә – программада катнашучыларга стандарт торак сатып алуга социаль түләү бирүне тәэмин итү;<br>яшь гаиләләргә торак алу өчен үз акчаларын, банкларның һәм шул исәптән торак алу өчен ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирүче башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру. |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2020-2025 еллар</td></tr>
<tr><td>Елларга бүлеп программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 774 000,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="3">Шул исәптән акчалар</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджетыннан</td><td>Федераль бюджеттан җәлеп итү планлаштырылган</td><td>Бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итү планлаштырылган</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>129 000,0</td><td>50 000,0</td><td>(*)</td><td>79 000,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>774 000,0</td><td>300 000,0</td><td>(*)</td><td>474 000,0</td></tr>
</table>
(*) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча чараны финанслау күләменә ел саен төгәллек кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td>Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:<br>2020 елда - 30 гаиләне; 2021 елда –30 гаиләне; 2022 елда – 30 гаиләне; 2023 елда – 30 гаиләне; 2024 елда – 30 гаиләне; 2025 елда – 30 гаиләне торак белән тәэмин итәргә;<br>яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү дәрәҗәсен арттыру өчен шартлар булдырырга;<br>торак өлкәсенә ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирүче банкларның һәм башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын, шулай ук гражданнарның үз акчаларын җәлеп итәргә;<br>яшьләрнең актив тормыш позициясен формалаштыру өчен шартлар тудырырга;<br>гаилә мөнәсәбәтләрен ныгытырга һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметергә;<br>Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә демографик хәлне яхшыртырга булышырга.</td></tr>
<tr><td>Программаның тормышка ашырылуын контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td>Программаның тормышка ашырылуын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе исеменнән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Аңлатма язуы

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын, Татарстан Республикасының «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Законы кысаларында дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт

программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында кабул ителә.

Программа яшь гаиләләргә – программада катнашучыларга торак сатып алуга социаль түләүләр бирүне күздә тота.

## 3 бүлек. Программаны тормышка ашыруның төп максатлары, бурычлары һәм сроклары

Программаның төп максаты булып билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүдә, торак сатып алуга социаль түләүләр бирү юлы белән, дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын тормышка ашыру тора.

Программаның төп бурычлары булып тора:

- яшь гаиләләргә – программада катнашучыларга стандарт торак сатып алуга социаль түләүләр (алга таба – социаль түләүләр) бирүне тәэмин итү;
- яшь гаиләләр тарафыннан торак алу өчен үз акчаларын, банкларның һәм шул исәптән ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирүче башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Программаны тормышка ашыруның төп принциплары булып тора:

- яшь гаиләләрнең программада катнашу иреклелеге;
- законнар нигезендә яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;
- яшь гаиләнең социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек акчасы булу;
- программа кысаларында федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан яки Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына яшь гаиләләр өчен ярдәм алу хокукын тормышка ашыру мөмкинлеге, тиешле чыганаклар булганда, торак шартларын яхшыртуга бары тик 1 тапкыр.

Яшь гаиләгә программада яки торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүне күздә тоткан теләсә кайсы башка программада (ярдәмче программада) катнашу хокукы бирелә.

Программаны тормышка ашыру срогы 2020-2025 еллар.

## 4 бүлек. Программа чаралары системасы

Программа чаралары системасын тормышка ашыру федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

Федераль дәрәҗәдә оештыру чаралары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының төп чарасын, региональ дәрәҗәдә - ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруны күздә тота.

Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә оештыру чаралары күздә тота:

1) Дәүләт заказчысы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь

хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын (алга таба-ярдәмче программа) тормышка ашыру турында килешүләр төзү;

2) ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруда катнашучы җирле үзидарә органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда катнашучы яшь гаиләләр турында мәгълүмат җыю һәм ярдәмче программада катнашучылар турында бердәм мәгълүмат базасы формалаштыру;

3) ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча күләмен ел саен билгеләү;

4) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен ярдәмче программада катнашу өчен сайлап алу һәм алар арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү;

5) яшь гаиләләргә социаль түләүләр сыйфатында бирелә торган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә банкларны сайлап алу;

6) яшь гаиләләр - ярдәмче программада катнашучылар өчен стандарт торак бирүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешмаларны сайлап алу (кирәк булганда);

7) үз вәкаләтләре чикләрендә ярдәмче программаны республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

8) Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын яктыртуны тәэмин итү.

Муниципаль дәрәҗәдәге оештыру чаралары күздә тота:

1) законнар белән билгеләнгән тәртиптә яшь гаиләләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

2) ел саен программада катнашу өчен яшь гаиләләрнең исемлеген формалаштыру;

3) ел саен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында программа чараларын тормышка ашыруга акча күләмен (булу шарты белән) билгеләү;

4) программада катнашучы яшь гаиләләрне исәпкә алуны оештыру;

5) билгеләнгән тәртиптә яшь гаиләләргә торак сатып алуга таныклыклар бирү;

6) программаның максатларын һәм бурычларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итү;

7) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторлары билгеләгән форматларга туры китереп, ЕГИССО системасында торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү;

8) Программада катнашучылар турында мәгълүмати-аналитик мәгълүматлар базасын формалаштыру;

9) программа чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын бүлеп бирүгә заявка формалаштыру;

10) программаны тормышка ашырылуына контрольне гамәлгә ашыру;

11) программаның тормышка ашырылуына мониторинг үткәрү, Дәүләт заказчысына тәкъдим итү өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материалларын әзерләү.

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның төп чыганаклары булып тора:

1) федераль бюджет акчалары (Ярдәмче программа чараларын финанслашу);

2) билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

3) бюджетка өстәмә керемнәрнең тиешле чыганаклары булганда, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары;

4) яшь гаиләләргә торак сатып алуга яки шәхси торак йорт төзүгә кредитлар һәм заемнар, шул исәптән ипотека торак кредитлары бирүче кредит һәм башка оешмалар акчалары;

5) яшь гаиләләрнең сатып алына торган торак урын бәясен өлешчә түләү өчен файдаланыла торган акчалары.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру механизмы яшь гаиләләргә - программада катнашучыларга социаль түләүләр бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуда өстәмә дәүләт ярдәме чараларын тормышка ашыруны күздә тота.

Яшь гаиләгә торак урын сатып алуга социаль түләү һәм бер бала туган (уллыкка алынган) очракта өстәмә социаль түләү программага 1 нче кушымтада күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә бирелә һәм файдаланыла.

Социаль түләүне бирү шарты булып яшь гаиләнең торак урын сатып алу өчен үзенең өстәмә акчалары булу тора. Яшь гаилә тарафыннан өстәмә акча сыйфатында шулай ук ана (гаилә) капиталы акчалары (акчаларның бер өлеше) файдаланылырга мөмкин.

Яшь гаиләнең программада катнашуы турындагы карарны, программага 2 нче кушымтада күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә, Башкарма комитетның вәкаләтле органы - Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча торак комиссиясе кабул итә.

Программада катнашу һәм социаль түләү бирү шарты булып яшь гаиләнең балигъ булган әгъзаларының Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары тарафыннан яшь гаилә әгъзалары турында персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирүе тора.

Ризалык «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә рәсмиләштерелгән булырга тиеш.

Социаль түләүне яшь гаиләгә җиткерү механизмы сыйфатында торак урын сатып алуга социаль түләү алу яки индивидуаль төзелеш объектын төзү хокукы турында таныклык файдаланыла, ул Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлеге (алга таба – торакны үстерү бүлеге) тарафыннан бирелә. Алынган таныклык социаль түләүләр бирү өчен каралган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен, аның хуҗалары тарафыннан Дәүләт заказчысы сайлап алган банкка тапшырыла, анда яшь гаилә әгъзасы исеменә социаль түләүне күчерү өчен билгеләнгән банк счеты ачыла. Яшь гаилә – таныклык хуҗасы торакны сатып алу урыны буенча банк белән банк счеты килешүе төзи.

Торакны үстерү бүлеге гамәлгә ашыра:

1) программада катнашучыларның үзара эшчәнлеген;

2) программаны тормышка ашыруда методик ярдәм күрсәтү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге заявкасын яклау;

4) Дәүләт заказчысы, вәкаләтле оешмалар, банк белән үзара эшчәнлекне тәэмин итү;

5) программа чараларының мониторингын һәм нәтиҗәлелеген бәяләүне оештыру;

6) Дәүләт заказчысына бирү өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материаллары әзерләү.

## 7 бүлек. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү һәм программа нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның һәм аңа федераль, республика бюджетларыннан бүлеп бирелгән акчалардан файдалануның социаль-икътисадый

нәтиҗәлелеген бәяләү Ярдәмче программада каралган критерийларны һәм индикаторларны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2020-2025 елларда программа чараларының уңышлы үтәлеше түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- торак өлкәсенә ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирә торган банкларның һәм башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын, гражданнарның үз акчаларын җәлеп итү;
- җәмгыятьтә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;
- гаилә мөнәсәбәтләрен ныгыту һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметү;
- ипотека торак кредиты бирү системасын үстерү;
- торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме формаларын киңәйтү һәм яшь гаиләләр өчен торак алу мөмкинлеген арттыру.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

«2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына
1 нче кушымта

«2020-2025 елларга
«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын (алга таба – программа) тормышка ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын (алга таба - ярдәмче программа) тормышка ашыруда катнашу өчен сайлап алынган вәкаләтле оешмалар һәм банклар аша, яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен билгели, алар торак урын сату-алу шартнамәсен (сату-алу шартнамәсен түләү беренчел торак базарында стандарт торак сатып алуга вәкаләтле оешма белән шартнамә бәясе составында күздә тотыла торган акчалардан тыш) (алга таба - торак урынга шартнамә) түләү өчен; беренчел торак базарында яшь гаилә мәнфәгатьләрендә стандарт торак сатып алуга вәкаләтле оешма белән шартнамәне түләү өчен, шул исәптән торак урын сату-алу шартнамәсе бәясен түләүгә (шартнамәдә каралган очракларда) һәм (яки) әлеге оешма хезмәтләренә түләүгә; торак сатып алу өчен торак, шул исәптән ипотека кредиты яки торак заемы алганда беренчел кертемне түләүгә; торак урын сатып алуга торак, шул исәптән ипотека кредитлары яки торак заемнары буенча бурычның төп суммасын һәм процентларны түләү (алга таба - кредитлар буенча бурычны түләү) өчен, әлеге кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләрне үтәүне кичектергән өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш, бурычның һәм процентларның төп суммасын түләү өчен; тиешле акчаларны эскроу счетына күчерү юлы белән, торак урынны өлешләп төзү объекты сыйфатында күздә тоткан өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе бәясен түләү (алга таба - өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе бәясен түләү) өчен җибәрелә ала.

2. Программада катнашучының – яшь гаиләнең социаль түләү алуга хокукы исемле документ – торак урын сатып алуга яки индивидуаль торак төзелеш объекты булдыруга социаль түләү алу хокукы турында таныклык (алга таба – таныклык) белән раслана, ул кыйммәтле кәгазь булып саналмый.

3. Федераль дәүләт программасында билгеләнгән форма буенча таныклык бирү Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла. Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча торак комиссиясе (алга таба – комиссия) карары нигезендә яшь гаилә планлаштырылган елда социаль түләү алырга теләк белдергән яшь гаиләләр исемлегенә кертелә.

Таныклыкларның бланкларын әзерләү Татарстан Республикасы бюджетының Ярдәмче программаны финанслауга каралган акчалары хисабына Дәүләт заказчысы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Таныклыкның гамәлдә булу срогы таныклыкта күрсәтелгән бирү датасыннан башлап 7 айдан да артмый.

5. Түбәндәге шартларга туры килә торган яшь гаилә, шул исәптән бер һәм аннан күбрәк баласы булган, ире яки хатыны Россия Федерациясе гражданы булмаган яшь гаилә, шулай ук Россия Федерациясе гражданы булган яшь атадан яки анадан гына торган һәм бер һәм аннан да күбрәк баласы булган тулы булмаган яшь гаилә (шул ук вакытта балалар ата-ана яки тулы булмаган гаиләдәге ата яки ана иждивениесендә булырга тиеш) программаны тормышка ашыру кысаларында социаль түләү алуга претендент була ала:

1) Дәүләт заказчысы тарафыннан яшь гаиләне планлаштырылган елда социаль түләү алуга претендентлар исемлегенә кертү турында карар кабул иткәндә ир белән хатынның яисә тулы булмаган гаиләдәге ата яки ананың яше планлаштырылган елның 1 гыйнварына торышы буенча 35 яшьтән артырга тиеш түгел;

2) әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә яшь гаилә торак урынга мохтаҗ дип танылган;

3) балаларны да кертеп, яшь гаиләнең барлык әгъзаларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәү;

4) гаиләнең кредит алырга мөмкинлек бирүче керемнәре яисә бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек башка акчалары булу.

Яшь гаилә таныклык бирү датасыннан һәм сатып алына торган торак урынга түләү, торак урын сатып алу өчен торак, шул исәптән ипотека кредиты яки заем алганда беренчел кертемне түләү, вәкаләтле оешма белән төзелгән шартнамәне, торак сатып алуга ипотека торак кредитлары яки заемнар буенча бурычның төп суммасын түләү һәм процентларны түләү хисабына аның банк счетына банкның акча күчерүе турында счетлар белән идарә итүченең боерыгы банк тарафыннан үтәлгән вакытка кадәр программада катнашучы дип танылa.

6. Торак урынга мохтаҗлар дигәндә 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган яшь гаиләләр, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә аларның даими яшәү урыны буенча 2005 елның 1 мартыннан соң, аларның торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелуына бәйсез рәвештә, гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар дип тану өчен Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясы белән билгеләнгән нигезләр буенча, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләр аңлашыла.

Яшь гаилә өчен торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләгәндә, социаль наем шартнамәләре буенча яшь гаилә әгъзалары биләгән яшәү өчен яраклы барлык торак урыннарның һәм (яки) яшь гаилә әгъзаларының милек хокукындагы торак урыннарның һәм торак урынның (торак урыннарның) бер өлешенең гомуми мәйданының суммар күләме исәпкә алына.

7. Программаны тормышка ашыру кысаларында, яшь гаиләне кредит алырга мөмкинлек бирә торган җитәрлек керемнәргә яисә бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен башка акчаларга ия дип тану тәртибе һәм шартлары программага 3 нче кушымтада билгеләнгән.

8. Социаль түләүдән файдаланып торак шартларын яхшырту хокукы яшь гаиләгә Программа кысаларында бары тик 1 тапкыр гына бирелә. Программада катнашу ирекле.

9. Социаль түләү түбәндәге күләмдә бирелә:

- Әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең 30 проценты – балалары булмаган яшь гаиләләр өчен;

- Әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең 35 проценты – бер һәм аннан күбрәк баласы булган яшь гаиләләр, шулай ук бер яшь атадан яки анадан һәм бер яки аннан күбрәк баласы булган тулы булмаган яшь гаилә өчен.

10. Социаль түләү күләмен алдан исәпләү әлеге Кагыйдәләрнең 11 пункты нигезендә билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы күләменнән, программада катнашучы – яшь гаилә әгъзалары саныннан һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гомуми торак мәйданының 1 кв. метр бәясе нормативыннан чыгып башкарыла. Социаль түләү күләмен исәпләү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының бәя нормативы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган Татарстан Республикасы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының уртача базар бәясеннән артмаган күләмдә Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

11. Социаль түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган торак урынның гомуми мәйданының күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

- ике кешедән торган гаилә өчен (яшь ир белән хатын яки бер яшь ата яки ана һәм бала) – 42 кв. метр;

- өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен (яисә бер яшь ата яки анадан торган һәм ике һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләр) – бер кешегә 18 кв. метр.

12. Социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$СтЖ = Н \times РЖ,$$

монда:

СтЖ – социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясе;

Н – әлеге Кагыйдәләрнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә торган гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының бәя нормативы;

РЖ – әлеге Кагыйдәләрнең 11 пункты нигезендә билгеләнә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме.

13. Социаль түләү күләме Дәүләт заказчысы тарафыннан социаль түләү алуга претендентлар – яшь гаиләләр исемлекләрен раслау датасына исәпләнә, таныклыкта күрсәтелә һәм аның гамәлдә булу вакыты дәвамында үзгәрешсез кала.

14. Программада катнашу өчен әлеге Кагыйдәләрнең 1 пункты нигезендә социаль түләүдән файдалану максатларында, торак, шул исәптән ипотека кредитлары яки торак заемнары буенча бурычның төп суммасын түләү һәм процентларны (әлеге кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләрне үтәүне кичектергән өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) түләү өчен социаль түләүдән файдаланудан тыш, яшь гаилә барлык гаилә әгъзаларының түбәндәге документларының төп нөсхәләрен һәм күчермәләрен даими теркәлү урыны буенча Башкарма комитетның район хакимиятенә (алга таба – район хакимияте) тапшыра:

1) яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында гариза (әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта) ике нөсхәдә (бер нөсхә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасын күрсәтеп гариза бирүчегә кире кайтарыла);

2) исемлек буенча яшь гаиләне әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны раслаучы документлар (программага 2 нче кушымта). Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны

раслаучы документ булып Башкарма комитет вәкаләтле органының тиешле карары тора (гариза бирүченең инициативасы буенча тәкъдим ителергә, шулай ук районнар хакимиятләренең запрослары буенча алынырга мөмкин);

3) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен раслаучы документларның күчермәләре;

4) язылышу турында таныклык күчермәсе (тулы булмаган гаиләгә кагылмый);

5) әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтада каралган форма буенча планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентларны – яшь гаиләләрне исемлеккә кертү турында гариза (торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм түли алу сәләтен раслау өчен кирәкле документларны теркәп) ике нөсхәдә (гаризаның бер нөсхәсе гаризаны аңа теркәлгән документларны кабул итү датасын һәм күрсәтеп гариза бирүчегә кире кайтарыла);

6) «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы яшь гаилә әгъзалары турында персональ мәгълүматларны эшкәртүгә нигезендә яшь гаиләнең балигъ булган әгъзаларының язмача ризалыгы;

7) гаиләнең балигъ булган һәр әгъзасының индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүен раслаучы документ күчермәсе;

8) гаиләнең кредит алырга мөмкинлек бирә торган җитәрлек керемнәре яисә исемлек буенча бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек башка акчалары булуын раслаучы документ (Программага 2 нче кушымта).

15. Социаль түләүне бурычның төп суммасын түләү һәм торак урын сатып алуга торак, шул исәптән ипотека кредитлары һәм торак заемнары буенча процентларны (бу кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләрне үтәүне кичектергән өчен башка процентлар, штрафлар, комиссияләр һәм пенялардан тыш) түләү өчен файдалану максатларында Программада катнашу өчен яшь гаилә Кагыйдәләрнең 2 - 5 пунктчалары нигезендә документларны, шулай ук түбәндәге документларны яшәү урыны буенча район хакимиятенә тапшыра:

- ипотека торак кредиты (заем) акчаларыннан файдаланып сатып алынган торак урынга милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе яки күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

- кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) күчермәсе;

- кредиторның (бурычка бирүченең) төп бурыч калдыгы суммасы һәм ипотека торак кредитыннан (заемнан) файдаланган өчен процентлар түләү буенча бурыч суммасы турында белешмәсе;

- яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны раслаучы документлар (гариза бирүченең инициативасы буенча тәкъдим ителергә, шулай ук район хакимиятләренең запросы буенча алынырга мөмкин).

16. Яшь гаилә исеменнән әлеге Кагыйдәләрнең 14, 15, 29, 31 пунктларында каралган документлар аның балигъ булган әгъзаларының берсе яисә, тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылырга мөмкин.

17. Торакны үстерү бүлеге әлеге Кагыйдәләрнең 14, 15 пунктларында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларны тикшерә һәм, календарь көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта, документларның тулы пакетын тапшыру датасыннан аларны комиссия тарафыннан карауга чыгара. Комиссия яшь гаиләне планлаштырылган елда программаны тормышка ашыруда катнашу максатында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында яисә танудан баш тарту турында карар кабул итә.

18. Кабул ителгән карар, календарь көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта, яшь гаилә әгъзаларына шәхсән хәбәр итү юлы белән яки почта бүлеге аша хат җибәрү юлы белән җиткерелә.

19. Яшь гаиләләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танудан һәм (яки) планлаштырылган елда социаль түләү алуга претендентларны – яшь гаиләләрне исемлеккә кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) яшь гаиләнең әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве, шул исәптән ир һәм хатынның берсе яки һәрберсе яисә тулы булмаган гаиләдәге атаның яки ананың 35 яшьтән өлкәнрәк булуы;

2) әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау;

3) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

4) социаль түләүдән яисә федераль бюджет акчалары хисабына дәүләт ярдәменең башка формаларыннан файдаланып торак шартларын яхшыртуга элек гамәлгә ашырылган хокук.

20. Программада катнашу турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итү әлеге Кагыйдәләрнең 19 пунктында каралган баш тарту нигезләре бетерелгәннән соң рөхсәт ителә.

21. Районнар хакимиятләре ел саен 1 майга кадәр, программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә торучы яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түли алу сәләтен тикшерәләр, планлаштырылган елдан алдагы елның 15 маена кадәр планлаштырылган елда социаль түләү алырга теләк белдергән яшь гаиләләр исемлеген формалаштыралар һәм торакны үстерү бүлегенә тапшыралар.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм түли алу сәләтен раслау өчен яшь гаилә 1 майга кадәр район хакимиятенә әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы 7 пунктчасында, шулай ук программага 2 нче кушымтаның 13-16 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында каралган документларны район хакимиятенә тапшырган вакытта яшь гаилә тарафыннан күрстелгән мәгълүматлар үзгәргән (шул исәптән гаилә составы, даими яшәү урыны, мөлкәт хәле үзгәргән) очракта, календарь көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта яшь гаилә язма рәвештә мондый үзгәрешләр килеп чыгу турында хәбәр итә. Район хакимияте календарь көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта, хәбәр ителгән көннән башлап, әлеге яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түли алу сәләтен билгеләү буенча кабаттан эш алып бара.

Аерылышкан очракта, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түли алу сәләтен раслау шарты белән, тулы булмаган яшь гаилә комиссия карары буенча программада катнашу өчен исемлектә кала.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм түли алу сәләтен ел саен тикшерү яки кабат билгеләү барышында, яшь гаилә программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түли алу сәләтен расламаса яки яшь гаиләне программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптән төшерү өчен нигезләрнең берсе ачыкланса, календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә комиссия мондый тикшерү тәмамланган яки тиешле нигезләр ачыкланган көннән башлап, яшь гаиләне программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән төшерү турында карар кабул итә. Яшь гаиләне программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптән төшерү турындагы карарда нигезләр күрсәтелергә тиеш.

Яшь гаиләне программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптән төшерү турындагы карар, ул кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 3 көн эчендә, әлеге карар кабул ителүгә мөнәсәбәтле яшь гаиләгә бирелә яки җибәрелә.

Исәптән төшергәннән соң яшь гаиләнең программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую хокукы яңадан барлыкка килсә, исәпкә кую гомуми тәртиптә һәм исәпкә куелуның яңа датасы белән башкарыла.

22. Яшь гаиләне программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптән төшерү өчен нигезләр:

1) яшь гаилә тарафыннан исәптән төшерү турында гариза бирү;

2) яшь гаиләгә әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган социаль түләү алу хокукын бирә торган нигезләрнең берсен югалту, шул исәптән ир белән хатынның яисә тулы булмаган гаиләдәге атаның яки ананың 36 яшькә җитүе;

3) башка муниципаль берәмлеккә даими яшәү урынына китү;

4) тапшырылган яки запрос буенча алынган документларда дөреслеккә туры килмәгән һәм исәпкә кую өчен нигез булып тормаган мәгълүматлар, шулай ук җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының исәпкә алу турындагы мәсьәләне хәл иткәндә хокуксыз гамәлләре ачыклану;

5) социаль түләүдән яисә федераль бюджет акчалары хисабына дәүләт ярдәменең башка формаларыннан файдаланып, торак шартларын яхшырту буенча гамәлгә ашырылган хокук.

23. Дәүләт заказчысының запросы буенча торакны үстерү бүлеге:

1) әлеге Кагыйдәләрнең 20 пункты нигезендә мохтаҗлыгын һәм түли алу сәләтен раслаган яшь гаиләләр турында мәгълүматларны, планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентлар – яшь гаиләләр исемлеген формалаштыру турында мәгълүматны 30 эш көне эчендә район хакимиятләренә җиткерә;

2) әлеге кагыйдәләрнең 20 пункты нигезендә яңартылган документлардагы мәгълүматларны тикшерүне гамәлгә ашыра һәм комиссия, календарь көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә, планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентларны – яшь гаиләләрне исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә;

3) планлаштырылган елдан алдагы елның 1 июненә кадәр, район хакимиятләре тарафыннан тәкъдим ителгән исемлекләрне хронологик эзлеклелектә, программаны гамәлгә ашыру кысаларында планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентларның – торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын раслаган һәм бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары булган һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасында каралганча, язма рәвештә планлаштырылган елда социаль түләү алырга теләк белдергән (алга таба – тиешле елда социаль түләү алырга теләк белдергән) яшь гаиләләрнең бердәм исемлегенә формалаштыра. Беренче чиратта күрсәтелгән исемлеккә 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган яшь гаиләләр, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк баласы булган яшь гаиләләр кертелә.

Башка бертигез шартларда яшь гаиләне программада катнашучылар исемлегенә кертү чиратын билгеләү өчен документлар тапшыру датасы хәлиткеч әһәмияткә ия.

Социаль түләүләр алуга претендентлар – яшь гаиләләр исемлегенең формасы Дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнә.

24. Дәүләт заказчысының запросы буенча торакны үстерү бүлеге Дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнгән срокларда заявка һәм җыелма исемлекне тапшыра.

25. Яшь гаиләләр түбәндәге нигезләр буенча планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентлар – яшь гаиләләр исемлегеннән төшереп калдырыла:

1) яшь гаилә тарафыннан исәпкә кую урыны буенча, планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга претендентлар – яшь гаиләләр исемлегеннән чыгару турында гариза бирелү;

2) әлеге Кагыйдәләрнең 21 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча;

3) бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары булмау;

4) аерылышу аркасында яшь гаиләнең әлеге Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

5) яшь гаилә тарафыннан әлеге Кагыйдәләрнең 28 пункты нигезендә таныклык алу өчен кирәкле документлар тапшырылмау;

6) яшь гаилә тарафыннан исәпкә кую урыны буенча программада катнашучылар исемлегеннән чыгару һәм социаль түләү хокукы турындагы таныклыкны кире кайтару турында гариза бирелү (торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек акчасы булмаган очракта).

Әлеге пунктның 1 һәм 3-5 пунктчалары программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптән төшерү өчен нигез булып тормый.

26. Торакны үстерү бүлеге:

- квартал саен хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр, ярдәмче программаның Дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнгән форма буенча социаль түләүләр бирүгә бүлеп бирелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану турында хисапны ярдәмче программаның Дәүләт заказчысына тапшыра;

- социаль түләүләр бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр алынганнан соң биш эш көне эчендә, тиешле елда социаль түләү алуга претендентларга – яшь гаиләләргә таныклык алу өчен документлар тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итә, шулай ук әлеге таныклык буенча бирелә торган социаль түләүне алу һәм аннан файдалану тәртибен һәм шартларын аңлата;

- социаль түләүләр бирү өчен билгеләнгән бюджет акчалары кергәннән соң бер ай эчендә, Дәүләт заказчысы тарафыннан расланган исемлек нигезендә чират тәртибендә социаль түләүләр алуга претендентларга – яшь гаиләләргә таныклыклар рәсмиләштерә һәм аларны бирә.

27. Яшь гаиләгә бирелә торган социаль түләү күләме таныклыкта күрсәтелә һәм аның гамәлдә булу срогында үзгәрешсез кала. Социаль түләү күләмен исәпләү таныклык бланкында күрсәтелгән таныклык бирү датасына башкарыла.

28. Программа чараларын финанслауга бүлеп бирелгән һәм социаль түләүләр алуга претендентларга – яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү өчен билгеләнгән акчалар нинди дә булса нигезләр буенча алынган очракта, акчаларның алынган суммасына таныклыклар Дәүләт заказчысы тарафыннан расланган социаль түләүләр алу өчен резервка кертелгән яшь гаиләләр исемлегендәге яшь гаиләләргә чират тәртибендә бирелергә тиеш.

29. Таныклык алу өчен, тиешле елда социаль түләү алуга претендент – яшь гаилә таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрне алганнан соң 15 көн эчендә, торакны үстерү бүлегенә таныклык бирү турында гариза (ирекле рәвештә) һәм программага 2 нче кушымтаның 1-4; 12-16 пунктларында күрсәтелгән документларны җибәрә.

Торакны үстерү бүлеге күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларны тикшерү эшен оештыра.

30. Таныклык бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) таныклык алу өчен кирәкле документларны тапшыруның әлеге Кагыйдәләрнең 28 пунктында билгеләнгән срогын бозу;

2) әлеге Кагыйдәләрнең 29 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру;

3) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

4) заем акчалары ярдәмендә сатып алынган торак урынның Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә уңайлыклары булмаган даими яшәү шартларына карата кулланыла торган санитария һәм техник таләпләргә туры килмәве.

31. Программада катнашучыда – яшь гаиләдә бирелгән таныклыкны алыштыруны таләп иткән хәлләр барлыкка килгәндә, яшь гаилә таныклык биргән органга, аны алыштыруны таләп иткән хәлләрне күрсәтеп һәм әлеге хәлләрне раслаучы документларны теркәп, аны алыштыру турында гариза бирә.

Күрсәтелгән хәлләргә таныклыкның югалуы (урлануы) яки бозылуы, яшь гаиләгә таныклыгын тиешле срокта банкка тапшырырга мөмкинлек бирми торган нигезле сәбәпләр керә.

Гаризаны алган көннән башлап 30 календарь көн эчендә таныклыкны биргән орган яңа таныклык бирә, анда алыштырылган таныклыкта каралган социаль түләү күләме һәм гамәлдә булуның калган срогына туры килгән гамәлдә булу срогы күрсәтелә.

